**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 7 июлендәге 2358 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 7 маендагы 1396 номерлы «Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплау өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яки) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасында грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасындагы грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 7 маендагы 1396 номерлы «Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплау өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яки) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5. Субсидияләр, шул исәптән бюджет турында карар (бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында карар) белән каралганнары хакында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – Интернет челтәре) Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләрен Вәкаләтле органга җиткергән көннән соң килә торган 10 эш көне эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла»;

1.2. 33 пунктта «288 922 сум» сүзләрен «293 737,36 сум» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карар белән кертелә торган үзгәрешләрнең йогынтысы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**